**Татарстан Республикасы**
**Азнакай муниципаль районы**
**Туйкә авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Туйкә авылы №52-28 11апрель 2022 ел

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Туйкә авыл җирлеге бүлегендә Туйкә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм бу мәгълүматларны гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен белешмәләр урнаштыру тәртибенә үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Указы нигезендә

Туйкә авыл җирлеге Советы карар итте:

1.«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Туйкә авыл җирлеге битендә Туйкә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм бу мәгълүматларны гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен белешмәләр урнаштыру тәртибенә түбәндәге редакциядәге, 2 пунктның “г” пунктчасын түбәндәге редакуциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«г) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы (мондый алыш-бирешнең суммасы) хезмәткәрнең (эшченең) һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль

районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.http://pravo.tatarstan.ruhttp://aznakayevo.tatar.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Рәис Закирова Р.Р.